ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 02.02.2022 г. Казань № 24/2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 19 мартындагы 40 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 23 ноябрендәге 2009 санлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 19 мартындагы 40 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 28 июлендәге 284/2020 санлы, 2020 елның 18 декабрендәге 686/2020 санлы, 2021 елның 3 ноябрендәге 612/2021 санлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.02.2022 № 24/2022 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 19 мартындагы 40 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.5.1 пунктында:

п) пунктчасында «салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызу челтәрләре» сүзләрен «су үткәрү һәм (яки) канализация челтәрләре, салкын суны транспортлау һәм (яки) агынты суларны транспортлау башкарыла торган су үткәрү һәм (яки) канализация челтәрләре озынлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле с) кызыл юлын өстәргә:

«с) су үткәрү һәм (яки) канализация челтәрләренең һәм (яки) корылмаларының милекчесенең транзит оешмаларына кертү критерийларына туры килүен раслаучы документларның күчермәләре һәм башка мәгълүмат.»;

2.8.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

«мөрәҗәгать итүченең су үткәрү һәм (яки) канализация челтәрләренең һәм (яки) корылмаларының милекчеләрен һәм (яки) аларның законлы хуҗаларын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 642 номерлы карары белән расланган Кайнар су белән тәэмин итү кагыйдәләрендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары белән расланган Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрендә каралган транзит оешмаларына кертү критерийларына туры килмәве (бу кызыл юл таләбе 2022 елның 1 сентябреннән гамәлдә була).».